СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**«12» декабрь 2024 ел** **№ 313**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә маневр фонды муниципаль торагын булдыру һәм бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Торакны махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торагына кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, маневр фонды муниципаль торагын формалаштыру һәм торак бирү тәртибен билгеләү максатыннан, Арча район Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә маневр фонды муниципаль торагын булдыру һәм бирү тәртибе турында нигезләмәне (кушымта) расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә маневр фонды муниципаль торагын исәпкә алуны йөкләргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында (https://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ ИНН 1609009529

Арча район Советының
12 декабрь 2024 ел, № 313
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә маневр фонды муниципаль торагын булдыру һәм бирү тәртибе турында нигезләмә**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Торакны махсуслаштырылган торак фондының махсуслаштырылган торагына кертү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Уставы нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә маневр фонды (алга таба - маневр фонды) торагын булдыру, бирү һәм алардан файдалану тәртибен билгели.

1.3. Маневр фонды - махсуслаштырылган торак фондының бер төре, аның торагы түбәндәгеләр өчен вакытлыча яки даими яшәү өчен билгеләнә:

1.3.1 социаль наем шартнамәләре буенча алар биләгән торак урнашкан йортны капиталь ремонтлауга яисә реконструкцияләүгә бәйле рәвештә, гражданнар;

1.3.2 банк яисә башка кредит оешмасы кредиты яки юридик зат тарафыннан торак сатып алуга бирелгән максатчан заем акчалары исәбеннән сатып алынган һәм кредитны яисә максатчан заемны кире кайтаруны тәэмин итүгә салынган әлеге торакка түләтү мөрәҗәгате нәтиҗәсендә торагын югалткан гражданнар, әгәр түләтү мөрәҗәгате вакытында мондый торак алар өчен бердәнбер булса;

1.3.3 бердәнбер торагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз дип танылган гражданнар;

1.3.4 торагы күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз булган гражданнар;

1.3.5. законнарда каралган очракларда, башка гражданнар

1.4. Маневр фонды күп фатирлы йортлардагы торактан (фатирлардан) һәм гражданнарның даими яшәве өчен яраклы башка торактан торырга, җирлек шартларына карата төзекләндерелгән булырга тиеш (билгеләнгән санитар һәм техник кагыйдәләргә һәм нормаларга, янгын куркынычсызлыгы таләпләренә, законнарның экологик һәм башка таләпләренә җавап бирергә тиеш).

1.5. Маневр фонды муниципаль милектәге һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының җирлекләр бюджеты акчалары исәбеннән сатып алынган буш торактан төзелә.

1.6. Маневр фонды составына кертелгән маневр фонды торак йортлары һәм торагы хосусыйлаштырылырга, алмашынырга, бүленергә, наемга тапшырылырга тиеш түгел.

1.7. Торакны маневр фондына кертү өчен торакны маневр фондына кертү һәм күрсәтелгән фондтан төшереп калдыру Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 26 гыйнварындагы 42 номерлы карары белән расланган торакны махсуслаштырылган торак фондына кертү кагыйдәләре нигезендәге тәртип һәм таләпләрне үтәү юлы белән гамәлгә ашырыла.

1.8. Маневр фонды торагын бирү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе утырышында карала.

1.9. Маневр фонды торагын карап тоту, агымдагы ремонтлау һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары, маневр фонды торагына наем шартнамәсенә кул кую датасына кадәр, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

1.10. Маневр фонды торагын алучы гражданнарны теркәү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

1.11. Әлеге нигезләмә белән җайга салынмаган мәсьәләләр гамәлдәге законнар нигезендә хәл ителә.

## 2. Маневр фонды торагын бирү нигезләре, шартлары һәм вакыты

2.1. Маневр фонды торагы бер кешегә кимендә алты квадрат метр торак мәйданы исәбеннән бирелә. Бер кешегә алты квадрат метрдан кимрәк мәйданлы торак бирү гражданнарның язма ризалыгы белән генә гамәлгә ашырыла.

2.2. Маневр фонды торагына наем шартнамәсе (2 нче кушымта) түбәндәге чорга төзелә:

2.2.1. Йортны капиталь ремонтлау яисә реконструкцияләү тәмамланганчы (мондый шартнамәне әлеге нигезләмәнең 1 пунктының 1.3.1 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар белән төзегәндә).

2.2.2. Түләү җибәрелгән торакны сатканнан соң аларны түләттерү нәтиҗәсендә торагын югалткан гражданнар белән исәп- хисап тәмамланганчы (мондый шартнамәне әлеге нигезләмәнең 1.3 пунктының 1.3.2 пунктчасында күрсәтелгән гражданнар белән төзегәндә).

2.2.3. Бердәнбер торагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз булган гражданнар белән исәп-хисап тәмамланганчы, Россия Федерациясе Торак кодексында, башка федераль законнарда каралган тәртиптә яки аларга Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда һәм тәртиптә муниципаль торак фонды торагы бирелгәнче (мондый шартнамәне әлеге Нигезләмәнең 1.3 пунктының 1.3 бүлегендә күрсәтелгән гражданнар белән төзегәндә).

2.4.4.Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вакытка (мондый шартнамәне әлеге нигезләмәнең 1.3 пунктының 1.3.4 бүлегендә күрсәтелгән гражданнар белән төзегәндә).

2.3. Маневр фонды торагына наем шартнамәсе төзелгән вакытның тәмамлануы әлеге шартнамәне туктатуга нигез булып тора.

2.4. Маневр фонды торагына наем шартнамәсенең гамәлдә булу вакыты, нигезләнгән сәбәпләр булганда, гариза нигезендә озайтылырга мөмкин.

2.5. Маневр фондының бушаган торагы әлеге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә бирелә.

3. Маневр фонды торагын наем шартнамәсе буенча бирү тәртибе

3.1. Маневр фонды торагын наем шартнамәсе буенча исәпкә алу һәм бирү турындагы мәсьәләне карау өчен гражданнарга түбәндәге документларны тапшырырга кирәк:

3.1.1 гаиләнең балигъ булган барлык әгъзалары тарафыннан имзаланган гариза (1 нче кушымта);

3.1.2 мөрәҗәгать итүченең һәм аның гаилә әгъзаларының шәхесен раслый торган документлар (паспор яисә аны алмаштыра торган башка документ);

3.1.3 мөрәҗәгать итүченең гаилә хәлен раслый торган документлар (никахлашу турында таныклык, никахны өзү турында таныклык, туу турында таныклык);

3.1.4. торакның яшәү һәм гомуми мәйданын һәм бирелү датасын күрсәтеп, шәхси финанс счеты;

3.1.5 мөрәҗәгать итүче һәм аның гаилә әгъзалары белән бергә торак урыннарында яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр булган документлар;

3.1.6 торакка хокук билгели торган документларның күчермәләре (БДКМРда документлар теркәлмәгән очракта - мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырыла);

3.1.7. Әлеге нигезләмәнең 1.3.2, 1.3.3 пунктлары нигезендә маневр фонды торагы бирелүнең бер шартын раслый торган түбәндәге документларның күчермәләре:

- ипотека турында шартнамә;
- мөрәҗәгать итүче тарафыннан банк яисә башка кредит оешмасы кредиты яки торак сатып алуга юридик зат тарафыннан бирелгән максатчан заем акчалары исәбеннән сатып алынган торакка түләтү турында суд карары (законлы көченә керү турында тамга белән) яки залог бирүче белән залог тотучы арасында залог тотучының таләпләрен залогка куелган торак исәбеннән канәгатьләндерү турында килешү;
- башкарма производствоны ачу турында карар;
-гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә торакны яшәү өчен яраксыз дип тану турында бәяләмә.

3.1.8 гражданның, шулай ук аның гаиләсенең балигъ булган барлык әгъзаларының аларның шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм алардан файдалануга язма рәвештә ризалыгы;

3.1.9 карар кабул итү өчен кирәкле башка документлар.

3.2 Гражданның, шулай ук аның гаиләсенең балигъ булган барлык әгъзаларының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә һәм алардан файдалануга ризалыгы булмау маневр фондының торагын бирү турындагы гаризаны караудан баш тарту өчен нигез булып тора.

Әлеге нигезләмәнең 3.1 пунктындагы 3.1.2, 3.1.3 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, төп нөсхәләрен күрсәтеп, күчермәләрдә тапшырыла.

Исәпкә алу (торак бирү) турында гариза биргән гражданга документларны кабул итеп алу турында расписка бирелә.

3.4. Маневр фонды торагы, әлеге нигезләмәнең 4.1 пункты нигезендә гражданнар тарафыннан гаризалар бирү датасыннан чыгып, чират тәртибендә бирелә.

3.5. Әлеге Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә тапшырылган документлар күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән алып 30 эш көне эчендә карала, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе утырышында әлеге нигезләмәнең 1.3 пунктында күрсәтелгән гражданнарга маневр фонды торагы бирү турында карар чыгарыла яисә гражданнарга маневр фонды торагын бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрелә.

3.6. Маневр фонды торагын бирү турында карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет гражданнарга кабул ителгән карар турында тиешле карар кабул ителгән вакыттан алып өч эш көне эчендә хәбәр итә.

3.7. Гариза бирүчегә түбәндәге очракларда маневр фонды торагын бирүдән баш тартыла:

3.7.1 гаризага әлеге нигезләмәнең 3.1 пунктында күрсәтелгән кушып бирелә торган документларны тапшырмау;

гражданнар тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган һәм (яисә) тулы булмаган мәгълүмат булу;

3.7.3 гражданның һәм (яисә) аның гаилә әгъзаларының милек хокукында яисә аннан файдалану хокукында башка тора гы бар (әлеге нигезләмәнең 1.3.2, 1.3.3 пунктларында күрсәтелгән гражданнар өчен),

3.7.4 граждан Россия Федерациясе Торак кодексының 95 статьясында күрсәтелгән гражданнар категориясенә керми.

3.7.5. маневр фондының буш торагы юк.

3.8. Маневр фонды торагына наем шартнамәсе Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе карары нигезендә гражданнарга маневр фондыннан торак бирү турында Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы җирлекләре тарафыннан төзелә (2 нче кушымта).

## 4. Маневр фонды торагыннан файдаланган өчен түләү

4.1. Маневр фонды торагы алган гражданнар билгеләнгән тәртиптә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертергә тиеш. Маневр фондында яшәүче гражданнар өчен торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме гамәлдәге

бәяләр һәм тарифлар буенча билгеләнә һәм муниципаль торак фонды яллаучыларының яшәү өчен түләүләре күләменнән арта алмый.

4.2. Маневр фонды торагында яшәүче гражданнар торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча гамәлдәге законнарда каралган ташламаларга хокуклы.

4.3. Маневр фонды торагында яшәүче гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә компенсацияләр (субсидияләр) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә гамәлдә булган гаиләнең тулаем керемен, яшәү минимумын исәпкә алып бирелә.

4.4 Бердәнбер торагы җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш булган, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз дип танылган гражданнарга бирелгән торак урыны өчен түләү алынмый.

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы территориясендә
маневр фонды торагы турындагы нигезләмәгә
1 нче кушымта

(форма)

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе рәисенә

_______________________________________

гражданнан_____________________________

(Ф.И.А. и. тулысынча.)

___________________________________,

адрес буенча теркәлгән:

_______________________________________

(почта индексы, тулы адрес)

__________________________________

_______________________________________

(элемтә өчен телефон)

Гариза

___________________________________________________________

бәйле рәвештә (маневр фонды торагын алу өчен сәбәпләр)

_______________________________________________________________

Сезне миңа ______ составындагы гаиләм белән маневр фонды торагын маневр фонды торагына наем шартнамәсе буенча бирүегезне сорыйм.

Мин һәм минем гаилә әгъзалары "Шәхси мәгълүматлар турында" 27.07.2006 № 152-ФЗ Федераль законның 9 статьясы нигезендә минем шәхси мәгълүматларымны автоматлаштырылган, шулай ук автоматлаштыру чараларын кулланмыйча эшкәртүгә, атап әйткәндә, "Шәхси мәгълүматлар турында" 27.07.2006 № 152-ФЗ Федераль законның 3 статьясындагы 3 пунктында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәбез.

Әлеге ризалык Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган тиешле мәгълүматны яисә күрсәтелгән мәгълүматны үз эченә алган документларны саклау сроклары беткәнчегә кадәрге чорга бирелә.

Мөрәҗәгать итүче ___________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы-булганда) тулысынча (имза)

Гаиләнең хокукка сәләтле әгъзалары:

1. _________________________________________________.

2. _______________________________________________.

(гаиләнең хокукка сәләтле барлык әгъзаларының имзалары)

"___" ____________ 20__ ел

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы территориясендә
маневр фонды торагы турындагы нигезләмәгә
2 нче кушымта (форма)

**Маневр фонды**
**торагына типлаштырылган наем шартнамәсе № _______**

_______________________________________________________________________________

(торак пунктның исеме) (көн, ай , ел )

______________________________________________________________________

(маневр фонды торагы милекчесенең исеме яки
______________________________________________________________________
аның исеменнән гамәлдә булган дәүләт хакимияте органы
______________________________________________________________________
Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органы
______________________________________________________________________
җирле үзидарә органы яки ул вәкаләт биргән башка
______________________________________________________________________,
органның документ исеме, датасы һәм номеры)

алга таба «Наемга бирүче» дип аталучы, бер яктан, һәм граждан,

______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

алга таба "Яллаучы" дип аталучы, икенче яктан, ________ 202__ ел, N __ торак бирү турындагы карар нигезендә түбәндәгеләр турында әлеге Шартнамәне төзеделәр.

## I. Шартнамә предметы

1. Наемга бирүче Яллаучыга һәм аның гаилә әгъзаларына түләү хисабына _______________(дәүләт, муниципаль – кирәклесен күрсәтергә) милектәге гомуми мәйданы ____ кв. метр булган фатирдан (бүлмәдән) торган, _______________, йорт.___, корп. ____ , фатир___ адресы буенча урнашкан торакны ___________ ел, №__ хокукны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык нигезендә анда вакытлыча яшәү өчен тапшыра.

2. Торак ____________________________ (йортны капиталь ремонтлауга яисә реконструкцияләүгә, бу бинаны түләтү нәтиҗәсендә торак урынын югалтуга, торак урынны гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз дип тануга бәйле рәвештә бирелгән - кирәкле күрсәтү) бәйле рәвештә бирелә.

3. Торак маневр фондына __________________карары нигезендә кертелгән.
(Дәүләт идарәсе яисә дәүләт идарәсе гамәлгә ашыра торган орган исеме)
муниципаль торак фонды, карар датасы һәм номеры)

4. Бирелә торган торакка, аның техник торышына, шулай ук андагы санитар-техник һәм башка җиһазларга характеристика торакның техник паспортында бирелә.

5. Яллаучы белән бергә торакка аның гаилә әгъзалары керә:

______________________________________________________________

(Яллаучының гаилә әгъзасы фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм аның белән туганлык дәрәҗәсе)

## II. Яллаучының һәм аның гаилә әгъзаларының хокуклары һәм бурычлары

6. Яллаучы түбәндәгеләргә хокуклы:

1) яшәү өчен торактан, шул исәптән гаилә әгъзалары белән файдалануга;

2) күпфатирлы йортта гомуми мөлкәттән файдалануга;

3) торакның кагылгысызлыгына һәм торактан ирекле мәхрүм итүгә юл куймауга.

Законлы нигезләрдә яшәүче гражданнарның ризалыгыннан башка беркем дә торакка үтеп керергә хокуклы түгел, федераль законда каралган тәртиптә һәм очракларда яисә суд карары нигезендә генә мөмкин. Торакта законлы нигездә яшәүче гражданнар торактан куылырга яисә файдалану хокукында чикләнергә тиеш түгел, Россия Федерациясе Торак кодексында һәм башка федераль законнарда каралган тәртиптә һәм нигезләрдә генә мөмкин.

4) әлеге Шартнамәне теләсә кайсы вакытта өзүгә;

5) Россия Федерациясе Торак кодексының 159 статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидияләр алуга.

Яллаучы законнарда каралган башка хокукларга ия булырга мөмкин.

7. Яллаучы түбәндәгеләргә бурычлы:

1) торактан Россия Федерациясе Торак кодексында билгеләнгән чикләрдә файдала914ырга;

2) торактан файдалану кагыйдәләрен үтәргә;

3) торакның сакланышын тәэмин итәргә;

4) торакны тиешле халәттә тотарга. Торакны үз белдеге белән үзгәртеп кору яисә яңадан планлаштыру рөхсәт ителми;

5) торакка агымдагы ремонт ясарга;

6) торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен (мәҗбүри түләүләр) вакытында түләргә. Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү бурычы әлеге Шартнамә төзелгән вакыттан барлыкка килә. Торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне вакытында кертмәү Россия Федерациясе Торак кодексының 155 статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә пеняләр алуга китерә;

7) торакның санитар-техник һәм андагы башка җиһазларның техник торышын карау өчен, шулай ук кирәкле эшләрне башкару өчен Наемга бирүче вәкилен алдан килешенгән вакытта торакка кертергә;

8) торакның яисә андагы санитар-техник һәм башка җиһазларның төзексезлеге ачыкланганда, кичекмәстән аларны бетерү буенча мөмкин булган чаралар күрергә һәм кирәк булган очракта, алар турында Наемга бирүчегә яки тиешле идарәче оешмага хәбәр итәргә;

9)торактан файдалануны күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитар-гигиена, экология һәм законнарның башка таләпләрен исәпкә алып, гамәлгә ашырырга;

10) әлеге Шартнамә өзелгәндә яисә туктатылганда торакны бушатырга. Торакны бушатудан баш тарткан очракта, Яллаучы һәм аның гаилә әгъзалары суд тәртибендә чыгарылырга тиеш;

11) торакны бушатканда, аны 3 көн дәвамында Наемга бирүчегә тиешле хәлдә тапшырырга, Яллаучы тарафыннан башкарылмаган һәм аның бурычларына керә торган торакны агымдагы ремонтлау бәясен түләргә, шулай ук торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча бурычны түләргә.

Яллаучы законнарда каралган башка бурычларны үти.

8. Яллаучы торакны алмаштыруны гамәлгә ашырырга, шулай ук аны наемга тапшырырга хокуклы түгел.

9. Яллаучының гаиләсе әгъзалары торактан Яллаучы белән беррәттән файдалану хокукына ия һәм әлеге Шартнамә буенча тигез хокукларга һәм бурычларга ия.

10. Яллаучы гаиләсенең хокукка сәләтле әгъзалары Яллаучы белән әлеге Шартнамәдән килеп чыга торган йөкләмәләр буенча уртак җаваплы була.

11.Яллаучы гаиләсенең әгъзасы булудан туктаса да, торакта яшәвен дәвам итсә, аның Яллаучы һәм аның гаилә әгъзаларында булган хокуклары сакланып кала. Күрсәтелгән граждан әлеге Шартнамәдән килеп чыга торган йөкләмәләр буенча мөстәкыйль рәвештә җавап бирә.

## III. Наемга бирүченең хокуклары һәм бурычлары

12. Наемга бирүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүне үз вакытында кертүне таләп итәргә;

2) Яллаучы тарафыннан торак законнарын һәм әлеге Шартнамә шартларын бозу очракларында, әлеге Шартнамәне өзүне таләп итәргә.
Наемга бирүче законнарда каралган башка хокукларга ия булырга мөмкин.

13. Наемга бирүче түбәндәгеләргә бурычлы:

1) янгын куркынычсызлыгы, санитар-гигиена, экология һәм башка таләпләргә җавап бирә торган хәлдә, башка затлар хокукларыннан азат һәм яшәү өчен яраклы торакны Яллаучыга тапшырырга;

2) торак урнашкан күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне тиешенчә тотуда һәм ремонтлауда катнашырга;

3) торак бинага капиталь ремонт ясарга;

4) торак йортны, андагы санитар-техник һәм башка җиһазларны кышкы шартларда файдалануга үз вакытында әзерләүдә катнашырга;

5)коммуналь хезмәтләр күрсәтүне тәэмин итәргә;

6) әлеге Шартнамәдә билгеләнгән срокларда, әлеге шартнамәнең 7 пунктындагы 11 пунктчасында каралган шартларны үтәп, Яллаучыдан торакны кабул итеп алырга.

Наемга бирүче законнарда каралган башка бурычларны башкара.

## IV. Шартнамәне өзү һәм туктату

14. Әлеге Шартнамә яклар килешүе буенча теләсә кайсы вакытта өзелергә мөмкин.

15. Яллаучы әлеге Шартнамәне теләсә кайсы вакытта өзәргә мөмкин.

16. Наемга бирүче түбәндәге очракларда суд тәртибендә әлеге Шартнамәне өзүне таләп итәргә мөмкин:

1) Яллаучының торак һәм (яисә) коммуналь хезмәтләр өчен 6 айдан артык түләмәве;

2) Яллаучы яисә аның гаилә әгъзалары тарафыннан торакны җимерү яисә зарарлау;

3) күршеләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен системалы рәвештә бозу;

4) торактан тиешле билгеләнештә файдаланмау.

17. Әлеге Шартнамә түбәндәге очракларда туктатыла:

1) йортны капиталь ремонтлау яисә реконструкцияләү тәмамлангач, түләтү нәтиҗәсендә торакны югалткан Яллаучы белән исәп - хисаплар, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак өчен Яллаучы белән исәп-хисаплар тәмамлангач (тиешлесен күрсәтергә);

2) торакны югалтканда (җимергәндә);

3) Яллаучы вафат булганда.

Вафат булган яллаучының гаилә әгъзалары йортны ремонтлау яисә реконструкцияләү, бу торакка түләтү мөрәҗәгате нәтиҗәсендә торакны югалтуга бәйле исәп-хисаплар, гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә яшәү өчен яраксыз дип танылган торак өчен исәп-хисаплар тәмамланганчы торактан файдалану хокукын саклыйлар.

## V. Шартнамә буенча түләү кертү

18. Яллаучы торак өчен түләүне Россия Федерациясе Торак кодексында каралган тәртиптә һәм күләмдә кертә.

## VI. Башка шартлар

19. Әлеге Шартнамә буенча яклар арасында барлыкка килергә мөмкин бәхәсләр законнарда каралган тәртиптә хәл ителә.

20. Әлеге Шартнамә 2 нөсхәдә төзелде, берсе Наемга бирүчедә, икенчесе Яллаучыда.

| | | | |
|---|---|---|---|
| Наемга бирүче | _______________(имза) | Яллаучы | ______________(имза) |

М. У.